# Безгә 3 яшь


# Нәсыйхәт

Җомга
7
март
2014
№26

Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән
Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы


**Моннан өч ел элек, 25нче февральдә “Нәсыйхәт“ газетасының беренче саны дөнья күргән иде. Аның тарихи миссиясе зур, чөнки ул сайлаган кыйбласыннан тайпылмый, халкыбызның бай рухи традицияләрен онытмыйча яши. Төрле темаларны колачлап, һәр өлкәгә тиешенчә игътибар бирергә омтыла. Дини яңалыклар, җәмгыятьтәге күп төрле проблемалар колачлана. Аның абруе көннән-көн үсә, дәрәҗәсе күтәрелә бара. Аңа иҗади эзләнү хас...**

**Газетабызны туган көне белән чын күңелдән тәбриклибез, рухи ныклык, очлы каләм, иҗат чишмәсенең саекмавын, бәхетле көннәр телибез!**



## Яңалыклар

### КУРСЛАРДА БУЛЫП КАЙТТЫ

√**Мәдрәсә җитәкчесе Габдрахман Хәбибуллин 17-20 февраль көннәрендә Россия Ислам Институтында узган квалификация арттыру курсларында катнашты.** Курсларны Согуд Гәрәбстаныннан килгән Согуд Абдуллатыйф алып барды. Аны уңышлы үтү уңаеннан, барлык катнашучыларга шәһадәтнамәләр тапшырылды.

### КУКМАРА МӘДРӘСӘСЕНДӘ КУНАКТА

√**Мәдрәсә вәкилләре Кукмара мәдрәсәсендә кунак булдылар.** Алар биредә мәдрәсә шәкертләре арасында үткәрелгән бәйгенең төп шаһитләре булдылар һәм уку-укыту тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

### КУРСЛАРДА КАТНАШАЧАКЛАР

√**8-9 мартта Россия Ислам Институты бинасында Мороккодан килгән, Пәйгамбәребезнең нәселеннән булган остаз Абдуррахим Лякрим дәресләр бирәчәк.** Мәдрәсә мөгаллимнәре дә әлеге курсларда катнашачак.

### БӘЙГЕ УЗАЧАК

√**9нчы март көнне 10.00 сәгатьтә мәдрәсә бинасында кичке бүлек шәкертләре (хатын-кызлар) арасында бәйге узачак.** Әлеге бәйгедә алты кешедән торган дүрт төркем катнашачак. Алар үзара белемнәре, зирәклекләре, җитезлекләре буенча көч сынашачак.

### ВӘГАЗЬ КИЧӘСЕНДӘ КАТНАШТЫ

√**26нчы февраль көнне мәдрәсә директоры Габдрахман Хәбибуллин Яңа Комазан авылында вәгазь кичәсендә катнашты.** Биредә ул авыл халкына нәсыйхәтләрен җиткерде һәм дини сорауларга җавап бирде.

### ҖОМГА НАМАЗЫН АЛЫП БАРДЫ

√**Мәдрәсә мөгаллимнәре тарафыннан авыл мәчетләрендә җомга намазлары укытыла.** Әлеге чараның максаты авылларда халыкның дин белән кызыксынуларын арттыру, имамнар белән аралашу, мәдрәсәгә яңа шәкертләр җәлеп итү. Чираттагы җомга Габдрахман хәзрәт тарафыннан “Изге Нур“ мәчетендә үткәрелде.

### СЕМИНАРДА КАТНАШТЫЛАР

√**Район мөхтәсибе Илһам хәзрәт, үзәк мәчет имам-хатыйбы Наил хәзрәт һәм мәдрәсә директоры Габдрахман Хәбибуллин 27нче февральдә Кама урманчылыгы авыл җирлегендә узган дини семинарда катнашты.** Биредә алар авылдагы дини тормыш һәм мәчет эшчәнлеге белән таныштылар.

### ТАНЫШТЫРАЛАР, ЧАКЫРАЛАР

√**Мамадыш мәдрәсәсе укытучылары район авыллары буенча йөрүне дәвам итә.** Бу эшнең максаты - районнарыбызда белемле, тиешле дәрәҗәле имамнар, Ислам нигезләренә өйрәтүче укытучылар һәм башка дин белгечләрен булдыру. Шул исәптән Мамадыш мәдрәсәсе вәкилләре тарафыннан район авыллары, мәктәпләре һәм мәчетләре буенча таныштыру-чакыру эшләре алып барыла.

# Үз мәзхәбебезне белик!

**Бөтен дөнья мөселманнары яңа меңьеллык алдыннан замандашларның каршылыгына очрады: әһле ислам яшәгән илләрдә дини экстремизм һәм кискен хәрәкәт итү (радикализм) вирусы җибәрелде. Алар вөҗдан ирегe гамәленең яңа рәвешләрен барлыкка китерде. Бүген традицион диннең рухи мохитен төрле деструктив агымнар чолгап алды.**

Мөгаен, боларның барысы да мөселманнарның арасын өзү, аларның рухи тормышында тотрыксызлык китереп чыгару өчен алдан уйлап хәрәкәт итүнең җимешләредер.

Шуңа күрә татар зыялылары, дәүләт вәкилләре белән берлектә үткәрелгән дин эшлеклеләренең тарихи җыенында мөселманнар арасында килеп туган хәлгә борчылу белдерелде. Анда мондый хәлдән чыгуның бер ысулы итеп эшләрне Әбү Хәнифә калдырган юнәлештә, ягъни хәнәфи мәзһәбендә алып баруның зарурлыгы турында әйтелде.

Хәнәфи мәзһәбе нәрсәне аңлата? Ислам динендә ул нинди урын тота?


Тарихка мөрәҗәгать итсәк, Әбү Хәнифә (699-767) дигән исем алган Ногман ибн Сабит данлыклы фикһ белгече булган. Аның исеменә әл-Имам әл-Әгъзам (Бөек Имам) дәрәҗәле титулы кушылган. Әбү Хәнифә сөнниләр мәзһәбенә нигез салган имамнарның иң өлкәне иде. Бу имамнар арасыннан фәкать Әбү Хәнифә генә Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с. г. в.) сәхабәләре белән очрашкан. Әбү Хәнифәнең варис булуы мәсьәләсенә шуның өчен дә зур әһәмият бирелә: ул заманның күренекле фикһ галимнәре әл-Әүзаи, Суфьян әс-Саури, Ләис ибн Саад, Мәлик ибн Әнәс аның дәрәҗәсенә дәгъва кыла алмадылар. Имамның никадәрле бөек галим булуын әле бүгенгә кадәр бәяләп бетерү мөмкин түгел. Әбү Хәнифәнең алымы аның мәзһәбен тормыш шартларына нык якынайта. Бары Әбү Хәнифәгә генә Әл-Имам Әл-Әгъзам дигән исем бирелүе һәм мөҗтаһид-мотлак (алар шәригатьтәге һәр сораугa мөстәкыйль рәвештә фәтва чыгара алганнар) дәрәҗәсенә ирешкән укучыларының булуы күп нәрсәләр хакында сөйли. Башка мәзһәбләргә нигез салган имамнардан аермалы буларак, бары Әбү Хәнифәгә җәмгыятьтә үзгәрешләр барган чорда үзенең фәтваларын чыгарырга туры килгән. Шуңа күрә дә хәнәфи мәзһәбе исламдагы иң түземле хокук мәктәбенә әйләнгән. Шуңа күрә гади мөселманнар да бу мәзһәбне үзләренә аңлаешлы, дип таный. Моннан исә Урта Азия, Алтын Урда, Госманлы дәүләтендә һәм Бөек Магуллар империясендә кешеләрнең хәнәфи мәзһәбен кабул итүләре шул сәбәптән икәнлеге ачыклана. Аларның нәселе хәзергә хәтле бу мәзһәбтә булуын дәвам итә.

Болардан тыш, Әбү Хәнифә көндәлек тормыш таләпләренә җавап бирә торган Коръән һәм сөннәткә нигезләнеп, мөселманнарның хокук системасын эшләгән беренче илаһият белгече. Нәкъ әнә шуңа күрә имам әш-Шәфигый: “Мөселманнар фикһтагы уңышлары өчен Әбү Хәнифәгә бурычлы”,- дигән. Дөрестән дә, Әбү Хәнифәгә кадәр фикһ дигән фән булмаган. Ул истихсан (хәерлесен өстен күрү) һәм кыяс (Коръән белән хәдискә таянып хөкем чыгару) ысулларын барлыкка китерде. Имам шәригать галимнәрен акыл һәм гаделлек юлы белән хөкем итәргә чакырды.

Хәнәфи мәзһәбендәге фикер хөрлеге нәтиҗәсендә Фәраби һәм Әбугалисина кебек дөнья күләмендәге галимнәр барлыкка килә. Аларның фәнгә керткән өлеше бәһаләп бетергесез. Әбү Хәнифә зыялы кеше буларак, ислам дине өндәгән әдәп-әхлак кагыйдәләрен үзенә алган. Бөек имам төннәрен гыйбадәттә үткәргән. Әбү Йосыфның хәбәр итүенчә, ул һәр төнне бер рәкәгатьтә тулысынча Коръәнне укып чыккан. Кайчакларда төнге һәм иртәнге намазларны бер тәһарәт алу белән укыган. Бервакыт бер кеше имамга: “Алладан курык”,- дигән. Бу сүзләрдән соң, Әбү Хәнифә калтырап китеп, агарынып һәм башын аска иеп: “Сиңа Аллаһының рәхмәте булсын! Кешеләр бу сүзләрне ишетүгә никадәрле мохтаҗлык кичерә!”- диде. Әбү Хәнифә үз заманының иң абруйлы дин белгече булган. Шәддад ибн Хәким аның турында: “Мин ул заманда аңа караганда да гыйлемлерәк кешене күрмәдем”, - дигән. Имам әш-Шәфигый: ”Кешеләр хокук фәнен Әбү Хәнифәдән өйрәнә” һәм “Кешеләр хокук фәнендә Әбү Хәнифә белән чагыштырганда балалар кебек кенә”,-дип белдергән.

Россия мөселманнары арасында хәнәфи мәзһәбе киң таралган булса да, Әбү Хәнифәнең карашлары һәм эшләү алымнары киң җәмәгатьчелеккә тулысынча билгеле түгел. Шуңа күрә бүгенге көндә Әбү Хәнифәнең дини мирасын өйрәнү аеруча мөһим гамәл булып тора. Безгә шуны аңлау мәслихәт: радикаль (кискен) идеологияне кайбер илләрдә һәм төбәкләрдәге кебек, бездә көч кулланып юкка чыгару мөмкин түгел. Бирердә аңа шундый шартлар тудыру зарури: бу идеологиягә ихтыяҗ барлыкка килмәсен һәм ул үз-үзен юкка чыгарсын. Ә исламның хәнәфи мәзһәбендә кискен идеологиягә урын юк. Кайбер экспертларның: “Хәнәфи мәзһәбе радикализмны тоткарлап торучы көч”,- дигән сүзләрендә хаклык бар. Бу мәктәп кешеләргә түземле һәм уртача караштa булуы белән аерылып тора. Шуны онытырга ярамый: динне акыл белән кабул иткәндә генә без Раббыбыз чакырган урталыкка ирешә алырбыз.

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН**



**Башка мәзһәбләргә нигез салган имамнардан аермалы буларак, бары Әбү Хәнифәгә җәмгыятьтә үзгәрешләр барган чорда үзенең фәтваларын чыгарырга туры килгән. Шуңа күрә дә хәнәфи мәзһәбе исламдагы иң түземле хокук мәктәбенә әйләнгән. Шуңа күрә гади мөселманнар да бу мәзһәбне үзләренә аңлаешлы, дип таный.**

# Син саф мәхәббәткә лаекмы?

*Әдәп, әхлак,*
*гүзәл сыйфат*
*Булсын сөйгән ярыңда*
*Мәңгелеккә*
*дан алырсың,*
*Гүзәл булыр таңың да.*
**Рәшидә Исхакый сүзләре**

Аллаһы Тәбәракә үә Тәгалә теләк-әмере нигезендә Адәм атабызның тиңе анабыз Хәувва дөньяга бар кылына. Адәм галәйһиссәламнең сулъяк кабыргасыннан. Адәм атабыз бу вакыйганы белеп торган. Анабыз Хәуваны бик тә ошаткан, ягъни аңа гашыйк булган. Шулай итеп беренче саф мәхәббәткә нигез салынган:

–Адәм атабызның кабыргасыннан (әгъзасының бер өлешеннән) анабыз Хәуваның кылынуы;

–анабыз Хәуваның күркәмлеге, буйсыннарының зифалыгы, йомшаклыгы, тышкы һәм гыйльме рух эчке матурлыгы…“

-атабыз Адәм (г.с.)нең һәр гамәлендә һәм эшендә беренче киңәшче һәм ярдәмче була алу сыйфаты;

-уйлар-фикерләр, хисләр һәм бер-береңнең кадерен белү уртаклыгы;

-иң мөһиме – Аллаh Раббыбызның олы рәхмәтләренең берсе ягъни нәселне дәвам итү сыйфаты белән бүләкләнгән булуы…

Атабыз Адәм (г.с.)нең нәфесе (теләге) килгәч, аларны бу гөнаһтан саклау нияте белән, Җәбраил фәрештә аларга никах укыды.

Әйе, бу фани дөньяда Җәнаби Хак Тәгаләнең бу бүләгенә ягъни саф мәхәббәткә аның лаеклылары гына ирешә. Нигә саф мәхәббәткә лаек булганнар бик тә аз? Һәркемгә ачык, бу катлаулы һәм тирән мәгънәдәге сорауга тиз генә җавап бирү мөмкин түгел. Азмы-күпме үзебезнең мөмкинлектән чыгып без бу сорауга Ислам гакыйдәсе һәм әхлагы нигезендә җавап бирергә уйладык. Әйе, бу сорау дөньяви фәннәрдә һәм матур әдәбиятта күп язылган, языла һәм язылачак. Безнең фикер буенча хәтта мәхәббәт төшенчәсе дә әлегә ачыкланып бетмәгән сораулар рәтендә кала бирә… Һәм киләчәктә дә ачыкланып бетүе икеле…

Ә хәзер иң алдан Ислам нигезләре күзлегеннән мәхәббәт төшенчәсенең нәрсә икәнен ачыкларга тырышыйк. Мәгълүм ки кешенең өч асылы бар: җаны, акылы һәм бәдәне. Бәдән ягъни безнең тән (әгъзалары белән бергә) яратылган балчыктан. Тәннең Аллаһы Раббыбыз рәхмәте белән ихтыяҗлары: ашау, эчү, чисталык, хәрәкәт, хезмәт итү, ял итү, иркәләнү һ.б. Ә җаныбызны Бөек Аллаh нурдан яралтты дип аңлаталар Ислам дине галимнәре. Җан мәңгелек буларак саф яки каралган булырга мөмкин диләр. Безнең фараз буенча җанның сафлыгы белән билгеле бер дәрәҗәдә бәйләнгән гомумән һәммә төрле мәхәббәтнең сафлыгы. Ә җанның төп ихтыяҗы, ягъни сафлыгы бәйләнгән Ислам дине нигезләрен ни дәрәҗәдә үтәүгә. Акыл яки баш мие күзәнәкләренең төп эшчәнлеге бәйләнгән безнең Ислам дине һәм фани дөньяны өйрәнә торган фәннәр буенча гыйлем алу дәрәҗәсенә. Һәм дә ки өстәп шуны әйтәсе килә, бу дөньяда кешенең яшәү рәвешенең төп юнәлешен Бөек Хак Тәгалә рәхмәте белән җаныбыз күрсәтә һәм шул исәптән саф мәхәббәт сораулары буенча да. Ә акыл шушы юнәлеш нигезендә тән ихтыяҗлары (вазыйфаларының берсе буларак) белән җитәкчелек итәргә тиеш. Моңа төп дәлил – әлмисак ягъни Аллаһы Раббел-Гыйззә белән җаннар арасындагы килешү. Әйе, һәр кеше бу дөньяга саф җан белән туа. Ягъни Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән һәр кеше дөньяга фитрый иман белән килә. Бу инде хәзерге фән казанышлары белән исбатланган: 1) компьютерлы рентген ярдәмендә гарәп телендә укыдылар: уң як үпкә өстенә кан тамырлары белән язылган “Лә иләһә илләллаһ“ кәлимәсен; 2) ә мөселман хирурглары йөрәк өстенә кан тамырлары белән гарәпчә язылган “Аллаh“ сүзен укыдылар. Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, кешенең асылы саф мәхәббәт белән билгеле бер тәртиптә бәйләнгәне күренә:

-ягъни тән ихтыяҗларының берсе Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән иң югары дәрәҗәгә җиткән иркәләнү хисе (шул исәптән нәселне дәвам итү белән бәйләнгән теләк һәм якынлык);

-каралмаган, ягъни саф җаннар арасында гына мөмкин саф мәхәббәт икәне;

-һәм тиешле гыйлем (бигрәк тә Ислам нигезләре буенча) алганнар арасында гына саф мәхәббәт нигезендә була ала Бөек Аллаh риза булырдай үзара зур хөрмәт һәм тирән ихтирам.

Ә хәзер тәкъдим итәбез үзебезнең төшенчәне: “Икенче җенестәге иманлы затка булган саф мәхәббәтебезне ягъни зур психик куәткә ия булган хисләребез, тойгыларыбыз һәм күңелләребез ача күренгәннәрне Бөек Хак Тәгалә риза булырдай эчке һәм тышкы ихтыяҗларыбызны үтәүгә юнәлтү дибез“. Һәм дә ки өстәп шуны әйтәсе килә тормыш тәҗрибәләре нигезендә:

-иң көчле ярату, ягъни эчкерсез мәхәббәт бары тик Хак Сөбханәһү үә Тәгаләгә юнәлгән булырга тиеш;

-хәтта ки ата-ана белән бала арасындагы мәхәббәт тә мөмкин илтергә бәхетсезлеккә, әгәр Аллаh Раббыбыздан ризалык булмаса ягъни ата-ана яки бала (булырга мөмкин өлкән яшьтә) Бөек Аллаһтан артык күреп яратса баласын яки ата-анасын;

-һәм һәркемгә шул мәгълүм булырга тиеш, кем җаныбыз әйтергә теләгәнен тыңламыйча акылсыз һәм сукыр мәхәббәткә иярә икән, ул бер дә бер көнне кара кайгыга гына бата…

Әйтәләр бит, җан тартмаганны тән тартмас дип. Ә тыңлыйбызмы җаныбызның акылга нәрсә әйтергә теләгәнен? Ул егетнең яки кызның һәм ул ир-атның яки хатын-кызның җаны сафмы? Чөнки каралган яки карала башлаган җаннарга ия кешеләрдән ерак йөрми мәкруһ һәм хәрам гамәлләр. Ягъни бу кешеләрдән көтәргә була җир йөзендәге һәртөрле явызлыкларны һәм заманави проблемаларны (әхлаксызлык, эчкечелек, җинаятьчелек, ана карынынннан башлап үтерүләр, наркомания һ.б.). Һәм иң төп сорау – бу зат (икенче җенестәге) минем ихлас күңелемдәге Аллаh бүләк иткән саф мәхәббәтемә лаекмы? Мәнә шушы сорауларга тулы җавап бирү йөзеннән сүземне башлыйм ерактан, ягъни кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләр системасыннан. Иң беренче, һәркем безгә милләтенә карамастан, билгеле бер дәрәҗәдә кардәш. Бу инде хәзерге заман галимнәре тарафыннан исбатланган:

– 1988 елда “Newsweek“ журналы молекуляр генетика өлкәсендә эшләгән галимнәрнең, ДНК күзәнәкләренә ясалган генетик анализга таянып, “җирдәге барлык хатын-кызларның да нәселләре – бер анадан“ дигән нәтиҗәсен игълан итә;

-1995 елда исә “Times“ журналы Аризона университеты генетигы Мишель Хаммерның төрле расаларга караган кешеләрнең Y-хромосомаларын тикшергәннән соң, “аларның барысының да нәселе бер атадан килә“, - дип яза. Һәм бу галим ягъни Хаммер: “Бу – җирнең төрле кыйтгаларында яшәүче кешеләр кешегә охшаган маймыллардан килеп чыкканнар дигән теориягә каршы килә“, - дип яза. Ягъни без (җир йөзендәге барча кешеләр) - Адәм атабыз һәм анабыз Хәувва балалары. Нигә мин бу сорауга тукталдым? Галәмнәргә мәрхәмәт буларак җибәрелгән Пәйгамбәребез (с.г.в.с.) бер хәдисендә әйтә: “Кызны диненә, байлыгына, чибәрлегенә, нәселенә карап сайлыйлар, иң хәерлесе – дине“, - дип. Инде сайлаган ярың милләтенә карамастан башка дин заты икән һәм бер-берегездән арына алмыйсыз икән, нәрсә эшләргә?

**КАМИЛ ХИСМӘТОВ, мәдрәсә шәкерте, гер спорты буенча Гиннесс китабы рекордчысы**

**(Дәвамы киләсе саннарда)**

# Дөнья яңалыклары

**«Ярдәм” мәчетендә татар теле курслары башланды**



Казандагы «Ярдәм” мәчетендә татар телен өйрәнү курслары башланды. Әлеге проект «Без - татарлар” дип атала. Дәресләр «Ярдәм” мәчетендә дүшәмбе һәм чәршәмбе көннәрендә 18.00 сәгатьтә башлана.

«Ярдәм” мәчете татар телен тиз арада өйрәнүне күз уңында тота, дип билгеләп узды бу гыйбадәтханә имам-хатибы Илдар хәзрәт Баязитов.

Курслар 3 ай дәвам итәчәк, алар түләүсез рәвештә башкарылачак. Дәресләр һәр атнаны кичке якта үтәреләчәк.

Курслар тәмамланганнан соң, сертификат биреләчәк.

**Татарстан мөфтие Украинадагы вәзгыять уңаеннан мөрәҗәгать белән чыкты**



«Украинадагы вакыйгалар битараф булмаганнар күңелендә хәвефле һәм шомлы хисләр уята. Күз алдыбызда миллионлаган кешеләрнең язмышы социаль тотрыксызлык һәм көч куллану корбанына әйләнә. Украина халкы өстенә гражданнар сугышы һәм бетмәс кан кою куркынычы килде. Моңа һич кенә дә юл куярга ярамый. Без барыбыз да кеше гомере һәм дәрәҗәсе сагында торырга тиеш. Бу - безнең һәркайсыбызның изге бурычы.

Аллаһы Тәгалә Украина халкына үз җирләрендә тынычлык сакларга һәм илне бәрәкәтле итәргә һәм аның үсешен булдырырга зирәклек бирсен иде”, - диелә ТР мөселманнары Диния нәзарәте сайтында бастырылган мөрәҗәгатьтә.

**Башкалабызда «Зур Казан» дигән басмаханә ачылды**

Башкалабыздагы «Ярдәм» тернәкләндерү үзәгендә «Зур Казан» дигән яңа басмаханә (типография) ачылды. Бу күренекле вакыйгага Татарстан Дәүләт советы депутаты, танылган



шагыйрь Роберт Миңнуллин һәм күп санлы каләм ияләре килгән иде.

Хәзер исә «Ярдәм” мәчетендә дингә каршы килми торган дөньяви китаплар да нәшер ителәчәк. Илдар хәзрәт сүзләренчә, биредә күбрәк күзләре күрүчеләр эшләячәк. «Зур Казан” басмаханәсе җитәкчесе – Илгиз Фатыйхов.

Шагыйрь Роберт Миңнуллин исә бүген Казан һәм Татарстан халкы өчен генә түгел, Россия кешеләренә дә истәлекле көн булуын билгеләп үтте....

Әлеге басмаханә ачылу тантанасында Татарстан Диния нәзарәтенең «Хозур” басмаханәсе җитәкчесе Ришат Хәмидуллин да килгән иде. Аңа сүз бирелгәч, ул Казанда типографияләрнең күп булуын, әмма гарәп һәм татар телләрендә китап бастыру белән шөгыльләнүчеләрнең юк дәрәҗәсендә икәнлеген белдерде. «Бу типографиянең безгә дә ярдәме булыр дип ышанам”,-диде Ришат әфәнде...

**Касыймдагы Хан мәчете мөселманнарга кайтты**



3 декабрь көнне Рязань өлкәсенең Касыйм (Ханкирмән) шәһәрендә XV гасырда төзелгән борынгы Хан мәчетен мөселманнарга кайтардылар.

– Бу ике катлы бина. 400 квадрат метр мәйданы бар. Шуңа барыбыз да сыябыз. Әлеге мәчет Петр I карары белән җимерелгән була, аның бары манарасы гына калган иде. 1700нче елларда Екатерина патшабикә аны яңадан торгызырга боерык бирә. 1938 елда исә ул музейга тапшырыла. Быел әлеге хәлгә нәкъ 75 ел тула.

**Чыганак: «Татар-информ»**

## МАМАДЫШ МӘДРӘСӘСЕНӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

**Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния Нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе шәкертләр туплавын дәвам итә.**

Белгечләр әзерләү көндезге һәм кичке уку рәвешендә алып барыла.

Көндезге бүлеккә ир-егетләр кабул ителә (шәһәрбездән һәм авыллардан). Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә **өч** тапкыр ашау-эчү белән тәэмин ителәләр. Уку вакыты–дүрт ел. Урта белем алу икенче лицей нигезендә алып барыла. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында диплом бирелә.

**УКЫРГА КЕРҮ ӨЧЕН КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕНӘ ТҮБӘНДӘГЕ ДОКУМЕНТЛАРНЫ ТАПШЫРЫРГА КИРӘК:**

1) Гариза
2) Белем турында таныклык
3) 086-формасында сәламәтлек турында белешмә
4) Паспорт (күчермә)
5) 3х4 үлчәмендә 4 фотосурәт
6) №26 формасында индивидуаль медицина картасы.

Намаз укырга өйрәнергә һәм дин белемен үзләштерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли. Бу бүлекләргә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь чиге куелмаган.

**Безнең адрес: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы 8/28,**
**Телефоннар:**
**3-19-17, 89172802391**

## ИГЪЛАН

“Насыйхәт” газетасы ислам тематикасына багышланган “Иң яхшы дини мәкалә” һәм “Иң яхшы дини шигырь” дип аталган конкурс игълан итә. Җиңүчеләрне истәлекле бүләкләр көтә. Һәр катнашучының иҗади җимешләре безнең газетабызда бастырылачак. Мәкаләләр һәм шигырьләр март-май айлары дәверендә кабул ителәләр. Аларны мәдрәсә электрон почтасына яки хат рәвешендә мәдрәсәгә җибәрүегез мөмкин.

**Безнең адрес: М. Җәлил ур. 8/28 эл. Почта: mamadysh-medrese@mail.ru**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 400 данә.**